*/Безнең спорт/*

## *Чаңгы юллары - 2022*



12 февральдә “Россия чаңгы юллары-2022” Бөтенроссия массакүләм чаңгыда узышу үткәрелде. Спорт чарасында безнең укучылар да актив катнашып, үзләренә тиешле араны чаңгыда йөгереп уздылар. Чаңгыда шуу сәламәтлеккә дә, кәеф күтәренкелегенә дә уңай йогынты ясый. Безнең укучылар арасында чаңгыда йөгерү буенча башлангыч сыйныфлардан III сыйныф укучысы **Хәбибрахманов Абдулла**, IV сыйныфтан **Насыйрова Кәүсәр**, V сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**, VI сыйныф укучысы **Йосыпов Рәсим**, VII сыйныфтан **Хәйруллин Айназ**, VIII сыйныфтан **Гафиятуллин Самат** алдынгы килүчеләрдән. Кызлар арасында алдынгылыкны башлангыч сыйныфлардан барысы да диярлек үз нормасын үтәде. Башкаларга да алардан калышмаска, чаңгыда йөрүгерү осталыкларын арттырырга киңәш итәбез.

***Виктория Нукина, X сыйныф укучысы***

## *Илдус – Республика беренчелегендә җиңүче!*

11-12 нче февраль көннәрендә Азнакай шәһәрендә 2005-2007 нче елгы яшүсмерләр арасында билбау көрәше буенча Татарстан Республикасы беренчелеге уздырылды. Бу бәйгедә катнашкан Илдус Камалов финалга чыгып, үз авырлыгында II урынны алуга иреште һәм март башында узачак Бөтенроссия беренчелегендә катнашу хокукы алды. Бу нәтиҗә Илдус өчен бик зур казаныш. Аңа алда торган ярышларда да җиңүләр яулап кайтуын теләп калабыз.

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***




*/Күңелле тәнәфес/*

## *Географияне беләсезме?*

1. Кайсы шәһәрдә аш пешерен була?
2. Кайсы күл кыргый диңгез исемен йөртә?
3. Кайсы капкага туп кертеп булмый?
4. Нинди култыкка әйбер кыстырып булмый?
5. Кем борыны бер дә өшеми?
6. Нинди бугаз сулый алмый?
7. Нинди чылбырны күтәреп булмый?
8. Кайсы утрауның исеме шул утрауда яшәүче хайван исемен йөртә?
9. Нинди дәүләтне башка киеп йөриләр?
10. Кайсы җир бервакытта да искерми?
11. Татарстанның кайсы шәһәрен табада кыздырып була?
12. Кайсы диңгезләр урыннары белән дә, температурасы белән дә, исемнәре белән дә капма-каршы?
13. Җир шарының кайсы урынында төньяктан гына барып була?
14. Нинди бугаз 2 диңгезне, 2 океанны, 2 ярымутрауны, 2 дәүләтне һәм 2 материкны бүлеп тора?

*/Безнең уңышлар/*



Февраль аенда ел саен Хәсән Туфан иҗаты буенча конкурста катнашып киләбез. Быелгы уку елында сәнгатьле сөйләү конкурсында III сыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр** I урынны алды, X сыйныф укучысы **Нукина Виктория** призер дипломы белән бүләкләнде.

**Туган телләр** көненә (День родного русского языка) карата уздырылган район конкурсында рус фольклор сәнгате буенча “Масленица” бәйрәм тамашасы күрсәтеп башлангыч сыйныфлар арасында I урынга лаек булдылар.

- Сәнгатьле сөйләм конкурсында призерлар: IV сыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр**, IX сыйныф укучысы **Шичкина Карина,**
Лауреатлар: V сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил.**
- Сочинениеләр конкурсында призерлар: V сыйныф укучысы **Залиева Вәсилә,** X сыйныф укучысы **Туктамышева Әминә.**
- Рәсем конкурсы буенча призер: IV сыйныф укучысы **Закирова Ләйсән,** лауреатлар – I сыйныф укучысы **Сафиуллина Гөлсем,** II сыйныфтан **Нурматова Асия .**

Шулай ук рус теле һәм әдәбияты буенча ел саен уздырыла торган **“Без срока давности”** дип атала торган Бөек Җиңүгә багышланган сочинениелар конкурсында катнашып **Залиева Вәсилә** призер булды. Укучыларыбызга киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз. Конкурсларда үз көчеңне сынарга чакырабыз.

***Нәҗметдинова Раушания, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина, Сара Насыйрова, Рузилә Мөхәммәтова

# Мәктәп хәбәрчесе

**№2** (№33) февраль 2022 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

*/Мәктәп тормышы/*

## *Әлифба бәйрәме*




Иң беренче кулга тоткан, белем дөньясына алып кергән дәреслекнең **Әлифба** икәне һәрберебезгә мәгълүм. Ә инде “балачак иленең кабатланмас бәйрәмнәреннән берсе нинди бәйрәм?" - дип сорасалар, бер дә икеләнмичә "Әлифба бәйрәме" дияр идем мин. Җир йөзендә кем генә булмасын, нинди генә хезмәт башкармасын, зур дулкынлану белән нәни кулларына Әлифба китабын алып, тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергәнендәге онытылмаслык мизгелне искә төшерәдер.

Әле кайчан гына, беренче сыйныфка кергән алты бөртек сабый, Әлифбаларын ачып, тәүге дәресләрен башлап җибәргәннәр иде. Инде менә Әлифбадан алган белемнәренә йомгак ясау вакыты да җитте. Безнең мәктәптә электән үк килә торган гадәт буенча, бу күңелле чара "Әлифба бәйрәме" рәвешендә уздырыла. Бу бәйрәм укучылар белән аларның укытучылары өчен генә түгел, әти-әниләр өчен дә зур тантана булып тора. Әлифбаны үзләштерү белән бергәттән укучыларның барысы да укырга, язарга, матур итеп сөйләшергә, әдәпле булырга, әлкәннәрне ихтирам итәргә, дус яшәргә, ярдәмчел булырга өйрәнделәр. Шушындый күркәм сыйфатларга ия булуларында аларның беренче укытучылары – Рузилә апаларының тырышлыгы зур.

4 нче февраль көнне узган **Әлифба бәйрәме** барышында укучылар төрле уен формасындагы биремнәрне уңышлы үтәделәр. Табышмакларга тиз арада җавап табып тапкырлыкта, уеннар уйнаганда бердәмлектә һәм оешканлыкта сыналдылар. Яңа интерактив тактадан да уңышлы файдаландылар. Чыннан да, Әлифба китабын тәгәлләү аларның беренче зур җиңүләре булды. Алдагы уку дәверендә дә укучыларыбыз шундый зиһенле, тырыш, һәм саусәламәт булсыннар дигән теләктә калабыз!

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## *23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне*




23 нче февраль – Туган иленә тугрылар көне дә диясем килә. Ватан төшенчәсен туган авыл, туган нигез, милләт, туган тел белән янәшә куя белүчеләр бәйрәме дә.

22 нче февраль көнне мәктәптә Ватанны саклаучылар көне хөрмәтенә урта һәм өлкән сыйныф егетләре арасында ярыш үткәрелде. Егетләребез “**Сапсан**” һәм “**Бөркет**” командаларына бүленеп ярыштылар. Бу ике төркем көчләре белән тигез иделәр. Берничә уен төре булды: шакмак ташу, турникта күтәрелү, туп белән чабу, автомат җыю, противогаз кию һәм башка көч сынау бәйгеләре үтте. Һәрбер егет үз көчен ярыш төрләрендә күрсәтергә тырышты. Җитезлек белән көч кенә дә түгел, егетләрнең тапкырлыгын да сынадылар. Фәнис абый хәрби темага сораулар да бирде. Уен уен булып кала, ярышта кемдер җиңә. Шулай итеп шактый ярыштан соң, “Бөркетләр” командасы җиңү яулады.

Бәйрәм азагында ТИН укытучысы Фәнис абый ГТО нормаларын тапшырган егетләргә алтын һәм көмеш значоклар тапшырды. Ахырдан безнең өчен тагын бер сюрприз булып алды. Директор Рафик абый мәктәпкә алып кайткан яңа корал – җәядән ату буенча мастер-класс күрсәтте. Безнең өчен яңалык булган бу коралдан барча укучылар да атып карадылар.

Егетләребез нинди генә көчле булсалар да, илебезнең тынычлыгын гына сакласыннар иде. Сугыш афәтләре генә килеп чыкмасын. Арабызда шундый җилдән җитез, көчле, ышанычлы, туган илен яратучы егетләрнең булуы мәктәпнең генә түгел, авылыбызның да горурлыгы.



***Бәйрәмнән репортажны Зөлфирә Сафиуллина әзерләде***

/Укучылар иҗаты/

## Юмарт кыш

Әй, кышым, юмарт та син
Кызганмыйсың аклыкны.
Салкында өшемәсен дип
Яптың калын юрганны.

Җир өсләре, күлләрне
Салкында туңдырмыйсың.
Җилләр үтәли йөрмәскә
Нигезләрне сылыйсың.

Ак күңелле булганга,
Карны күп яудырасың.
Дөньяга аклык биреп,
Сафлыкны арттырасың.

***Хәнифә Хәбибрахманова, V сыйныф укучысы***

---

## Кыш ахыры

Тиздән ак кыш та китәр
Җылы яшел яз җитәр.
Карлар һәм бозлар эреп
Гөрләвек булып китәр.

Агызырбыз көймәләр
Итекләргә су кертеп.
Тик әлегә кар белән
Көрәшәм көрәк белән.

Буран уйный көн саен.
Кар көрим яуган саен.
Мин әлегә бирешмим
Чөнки эштән курыкмыйм.

Яз барыбер җитәчәк,
Яшел әләм әләчәк.
Төгәл белмим вакытын
Күрсәтер әле киләчәк.

***Вәсилә Залиева, V сыйныф укучысы***

/Безнең уңышлар/




## Сара – республика призеры!

“Гыйлемле кеше – иң бай кеше” – ди халык әйтеме. Тик, малдан аермалы буларак, белемне сатып алып булмый. Әлбәттә, белем алуга сәләт табигатьтән бирелгән зур бүләк. Ләкин белем үрләрен яулау тырышлык, максатчанлык, ихтыяр көче кебек сыйфатлардан башка мөмкин түгел. Моны безнең чыгарылыш сыйныф укучысы **Насыйрова Сара** быел тагын бер кат раслады. Без аның уку дәверендә ирешкән күпсанлы нәтиҗәле урыннарына күнеккән идек инде. Инде менә Сара **рус әдәбияты буенча** районда ничә еллардан бирле җиңү яулап килгәннән соң, быелгы олимпиададан **республика призеры** исемен алып кайтты. Бу нәтиҗә безнең мәктәп өчен генә түгел, районыбыз өчен дә дәрәҗәле җиңү булды.

Сараның уңышы рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Нәҗметдинова Раушания апаның** да белем бирү осталыгын күрсәтә. Үз хезмәтеңә карата җаваплы караш, бердәм тырышлык булганда гына шундый югары нәтиҗәләргә ирешү мөмкин. Сарага чыгарылыш имтиханнарын югары билгеләргә тапшыруын, ә Раушания апага һөнәри уңышлар теләп калабыз.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту буенча директор урынбасары.***

## Муса Җәлилне искә алдык




15 нче февраль мәктәптә герой шагыйрь **Муса Җәлилнең туган көненә** багышланган сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Бу көнне Җәлилнең тоткынлыкта күрсәткән батырлыклары, Ватанына булган мәхәббәтенең иҗатында чагылуын тагын бер кат искә алдык. Муса Җәлилне дөньяга танытхан иҗат җимеше – аның тоткынлыкта язылган 93 шигырьдән торган “Моабит дәфтәрләре”. Аларның һәрберсе батырлык, туган илне ярату, антка тугрылык турында.

***Виктория Нукина, Х сыйныф укучысы.***

## Туган телләр көне



21 нче февраль дөньякүләм дәрәҗә-дә туган телләр көне буларак билгеләп үте-лә. Быел да, башка еллардагы кебек, мәк-тәптә бу чара авыл китапханәчеләре кат-нашында узды. Иске Әдәм авылы китапха-нәчесе Равия апа Таһирова башлангыч сыйныфлар белән ачык чара уздырды. Китапханәче апалары балалар өчен язылган китаплар, күренекле язучылар белән таныштырды. Сәнгатьле итеп төрле әсәрләрдән өзекләр укыды. Сораулар бирде, укучылар белән җылы әңгәмә алып барды. Телебезгә сакчыл караш, аны саф итеп саклау, ана телендә дөрес һәм чиста сөйләшү, җыйнак итеп аңлата белү әһәмиятен искәртү өчен кирәк бу көн. Ә гомумән алганда, **безнең һәр узмыш көнебез Туган тел көне булырга тиеш**!

***Әминә Туктамышева,Х сыйныф укучысы***

/Чал тарихта эзле без!/

## “Ватан сагында” проектының беренче нәтиҗәләре



Газетабызның узган санында Бөек Ватан сугышыннан соң армиядә хезмәт иткән авылдашлар буенча мәгълүмат базасы булдыру максатыннан “Ватан сагында” проектын башкару игълан ителгән иде. Инде менә башкарылган эшкә беренче нәтиҗәләр чыгару мөмкин булды. Проектны тормышка ашыруда мәктәпнең күп укучылары катнашты. Материаллар авылда яшәүче элеккеге солдатлар буенча гына түгел, читтә яшәүче авылдашлар белән элемтәгә чыгып та тупланды. Гомумән алганда, 1948-2020 нче еллар арасында армия сафларында хезмәт иткән 124 Түбән Майна егете турында фоторәсемле белешмәләр тупланды. Алардан спортзалда махсус зур күргәзмә булдырылды. Фотосыз материаллар һәм башка авыллардан чыгышлы солдатлар да исәпләнде. Аларны да санаганда барлыгы 140 ка якын солдат буенча материал җыелды.

Проектны тормышка ашыруда аеруча актив рәвештә түбәндәге укучылар катнашты:

- башлангыч сыйныфлардан Закирова Ләйсән белән Насыйрова Кәүсәр;
- урта буыннан Гафиятуллин Фаил, Хәйруллин Айназ, Гафиятуллин Самат;
- өлкән сыйныфлардан Сафиуллина Зөлфирә, Туктамышева Әминә, Насыйрова Сара.

Әлеге укучылар барысы да мәктәпнең грамоталары белән бүләкләнде.

“Ватан сагында” проекты әле төгәлләнгән дип әйтеп булмый. Чөнки берничә дистә авылдашларның армия хезмәте турында мәгълүмат җыелмаган килеш кала бирә. Димәк, актив һәм эзләнүче укучыларны бүләкләүләр әле алда.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

/Безгә кунак килде/

## Хәрбиләр белән очрашу




15 нче февраль – безнең илнең хәрби тарихындагы истәлекле даталарның берсе. Бу көнне, 9 ел дәвамында барган сугыштан соң, совет гаскәрләре Әфганстан иленнән чыгарыла. Шушы вакыйгага уңаеннан 15 нче февраль көнне мәктәпкә Әфганстанда булган, һәм шулай ук ракета, чик буе гаскәрләрендә хезмәт иткән солдат-ветераннар **Абдуллин Ф.М.** белән **Бобов А.И.** килде. Укучылар белән очрашуда алар хәрби хезмәтнең кыенлыклары, шул ук вакытта Туган илеңне саклауның мактаулы бурыч булуы турында сөйләделәр. Үзләре хезмәт иткән чордагы хатирәләре белән уртаклаштылар. Һәр гаскәр төренең үзенә генә хас сыйфатлары бар икән. Әлбәттә инде, хәрби хезмәт күп төрле авыр сынаулар белән бәйле. Аларны үзеңне сынатмый үтәр өчен хәрби кеше һәм яктан да камил булырга тиеш. Килгән кунаклар очрашуда катнашкан укучыларга физик яктан да, рухи яктан да көчле булырга кирәклеген искәртеп үттеләр.

***Самат Гафиятуллин,VIII сыйныф укучысы.***

/Котлыйбыз!/

## ТУГАН КӨНЕҢ БЕЛӘН!



Мәктәбебездә озак еллар дәвамында математика фәне серләренә төшендерүче, дистә елдан артык завуч эшен башкарган **Хәсәнова Ризидә апаны** олы юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Хөрмәтле Ризидә апа! Сезнең тынычлыкта, иминлектә, ныклы сәламәтлек белән озак еллар яшәвегезне телибез. Укучыларыгыздан һәрвакытта да җылы рәхмәт сүзләре генә ирешеп торсын.

Февраль аенда туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыздан I сыйныфтан Камалов Илнурны, III сыйныфтан Донсков Артурны, Хәбибрахманов Абдулланы, V сыйныфтан Хасанов Станиславны, VI сыйныфтан Йосыпов Рәсимне, IX сыйныфтан Сидоров Романы туган көннәре белән котлыйбыз! Укчыларыбызның тәртипле, тырыш, көчле шәхесләр булып үсүләрен телибез!

***“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***